КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 декабрь г.Казань № 1178

2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында

Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге үсешенең төп өстенлекләрен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу карар белән расланган 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы нигезләмәләрен Татарстан Республикасы милке хокукында акцияләре (өлешләре) булган инвестиция эшчәнлеге субъектларына ирештерергә.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына ел саен тиешле елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы белән билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген, төп куллану товарлары буенча базар сыешлыгы фаразын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, 90 көн эчендә Татарстан Республикасы инвестицион сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә, Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы белән билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген формалаштыру алымнарына үзгәрешләр кертү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

«Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумының өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 25 ноябрь, 925 нче карарына кертелә торган үзгәрешләрне эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга билгеләнгән тәртиптә кертергә.

5. 2020 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2018 ел, 28 декабрь, 1254 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 20 декабрь, 1178 нче
карары белән расланды

2020 – 2022 елларга
Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы (алга таба – Меморандум) 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген үстерүнең төп өстенлекләрен билгели.

1.2. Меморандум инвестиция эшчәнлегендә катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру өчен раслана һәм 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең стратегик максатына ирешүгә юнәлдерелә: Татарстан-2030 – глобаль көндәшлеккә сәләтле тотрыклы төбәк, «Идел – Кама» үсеш полюсы драйверы (төп үсеш чыганагы). Татарстан – кеше капиталын, институтларны, инфраструктураны, икътисадны, тышкы интеграцияләүне (Россиянең төп Евразия төбәге) һәм эчке киңлекне үзара бәйләнгән итеп үстерү сыйфаты буенча лидер; үсеш темплары алга киткән, халыкара хезмәт бүленешенә кертелүе югары булган төбәк.

1.3. Меморандум инвестиция эшчәнлеге субъектлары тарафыннан инвестиция эшчәнлеге планнары эшләнгәндә һәм расланганда нигез сыйфатында тәкъдим ителә.

1.4. Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеге белән идарә итү буенча дәүләт сәясәтен эшләү функцияләрен тормышка ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы, шулай ук Меморандум нигезләмәләрен тормышка ашыру өчен җаваплы үзәк булып Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Координатор) тора.

1.5. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы инвестицияләр җәлеп итү, инвестиция проектларын алып бару һәм тормышка ашыру, дәүләт-шәхси партнерлык мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы булып тора.

1.6. Татарстан Республикасы Инвестиция советы Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре буенча күмәк киңәшмә орган булып тора.

1.7. Меморандум нигезләмәләренең үтәлешен мониторинглауны Координатор гамәлгә ашыра.

1.8. Меморандум тексты Татарстан Республикасының ачык мәгълүмат ресурслары составына кертелә.

## II. Инвестицион сәясәтнең өстенлекле юнәлешләре

2.1. 2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасы инвестицион сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәр чорга Россия Федерациясен үстерүнең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы белән билгеләнгән түбәндәге юнәлешләр буенча илкүләм максатлар нигезендә билгеләнгән илкүләм проектларга (программаларга) туры килә торган инвестиция проектларын тормышка ашыруга булышлык күрсәтү: демография, сәламәтлек саклау, мәгариф, торак һәм шәһәр мохите, экология, куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары, хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү, фән, цифрлы икътисад, мәдәният, кече һәм урта эшмәкәрлек һәм индивидуаль эшмәкәрлек инициативасына булышлык күрсәтү, халыкара кооперация һәм экспорт;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыруга булышлык күрсәтү буенча эшче төркем турында» 2018 ел, 15 сентябрь, 1093 нче карары нигезендә төзелгән яңа инвестиция проектларын тормышка ашыруга булышлык күрсәтү буенча эшче төркем хуплаган инвестиция проектларын Татарстан Республиксы территориясендә тормышка ашыруга булышлык күрсәтү;

2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенең инвестицион сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә җавап бирә торган инвестиция проектларын Татарстан Республиксы территориясендә тормышка ашыруга булышлык күрсәтү;

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел тулуга багышланган чаралар кысаларында тормышка ашырыла торган Татарстан Республикасының тарихи һәм рухи мирасын саклап калу буенча инвестиция проектларын тормышка ашыруда булышлык күрсәтү;

эшмәкәрлекне үстерү;

сакчыл җитештерү ысулларын кертү;

инвестицияләр җәлеп итү һәм республика җитештерүчеләре продукциясен яңа базарларга чыгару өлкәсендә Россия Федерациясе төбәкләре һәм чит ил партерлары белән хезмәттәшлекне үстерү, халыкара икътисадый кооперация киңлеген актив куллану;

электрон сәүдәне үстерү;

нефть-газ химиясе һәм машина төзелеше комплексларында эре югары технологияле проектларны тормышка ашыру;

республика цифрлы энергетикасының үз эченә генерацияне, тапшыруны һәм сатуны алган бердәм структурасын формалаштыруга юнәлдерелгән инвестиция проектларын тормышка ашыру;

эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү инфраструктурасын, шул исәптән махсус икътисадый зоналарны, алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен, инновацион фәнни-технологик үзәкләрне, технопаркларны, индустриаль паркларны, сәнәгать мәйданчыкларын үстерү;

авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, экспорт өчен билгеләнгән авыл хуҗалыгы (шул исәптән хәләл) продукциясен җитештерүне

арттыруга юнәлдерелгән инвестиция проектларын тормышка ашыру;

алу дәрәҗәсе югары булган инвестиция проектларын тормышка ашыру;

цифрлы икътисадны формалаштыру һәм үстерү;

Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыручы предприятиеләргә (оешмаларга) салым ташламалары бирү юлы белән, шул исәптән махсус инвестиция котрактлары кысаларында, масштаблы инвестиция проектларын тормышка ашырганда җир кишәрлекләрен арендага торглар үткәрмичә бирү юлы белән дәүләт ярдәме күрсәтү, шулай ук законнар нигезендә инвестиция проектларына булышлык күрсәтүнең башка рәвешләре.

2.2. Инвестицион сәясәтнең Меморандум белән билгеләнгән юнәлешләренә, социаль-икътисадый үсешнең нәтиҗәләрен һәм яңа өстенлекләрен исәпкә алып, шулай ук законнарга кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

## III. Инвестиция эшчәнлеге субъектлары

Инвесторлар, заказчылар, подрядчылар, инвестиция эшчәнлеге объектларыннан файдаланучылар һәм инвестиция эшчәнлегенең башка катнашучылары сыйфатында булган, шул исәптән технополис территориясендә инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган физик һәм юридик затлар, шул исәптән чит ил физик һәм юридик затлары, шулай ук чит ил федератив дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләре, халыкара оешмалар инвестиция эшчәнлеге субъектлары булырга мөмкин.

## IV. Инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге

Инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге тәртибе законнар кысаларында билгеләнә һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары тарафыннан Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә эшләнелә торган регламентлар белән билгеләнә.

## V. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары бурычлары

2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге җирле үзидарә органнарының Меморандум белән билгеләнә торган төп бурычлары түбәндәгеләр була:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан үз компетенциясе чикләрендә инвестиция һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген

алып бару өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән иң яхшы төбәк, федераль һәм чит ил тәҗрибәләрен гамәлгә кертүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын үтәү йөзеннән эшләнгән илкүләм проектлары чараларын тормышка ашыруны һәм төбәккә караган максатчан күрсәткечләрнең план буенча мәгънәләренә ирешүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасындагы килешүләр белән билгеләнгән Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләрен үтәү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасының инвестиция проектларын үстерү буенча индивидуаль карталар (бизнес-проектларның аерым этапларын тормышка ашыру өчен җавап бирүче үтәүчеләрне һәм аларның конкрет вакытларын билгели торган документ) булдыру һәм алып бару.

---